**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «15» мартыннан № 69

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәге – Яңа Чишмә авылыннан 11 километрдан ераграк урнашкан авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 03 июнендәге 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы составына керүче, ерак торак пунктларда яшәүче авыл халкын беренче чиратта кирәкле товарлар белән тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне башкаручы физик затларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, һәм Россия Федерциясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм кайбер актларның нигезләмәләрен гамәлдән алынган дип санау турында» Россия Федерциясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасы авыл торак пунктларына кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 ноябрендәге 887 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәге – Яңа Чишмә авылыннан 11 километрдан ераграк урнашкан авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 03 июнендәге 242 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- сайлап алуда катнашучылар Россия Федерациясендә активлар белән арадаш (офшор) биләү өчен кулланыла торган дәүләт һәм территорияләрнең устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яисә читләтеп катнашу өлеше 25 проценттан артмаган (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлеккә кертелгән чит ил юридик затлары булырга тиеш түгел. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов